Дүртенче чакырылыш Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районы Советының икенче утырышы

Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районы Советы
КАРАРЫ

30 сентябрь, 2020 ел № 13

«Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районында Күн авылына керү юлында автомобиль юлы төзү» объекты буенча территорияне планлаштыру һәм ызанлау проектын раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы уставы нигезендә, 2020 елның 10 июнендәге гавами тыңлаулар беркетмәсен һәм «Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районында Күн авылына керү юлында автомобиль юлы төзү» объекты буенча территорияне планлаштыру проекты һәм ызанлау проекты буенча гавами тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмәне исәпкә алып, **Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советы карар чыгарды:**

1. Электрон чыганактагы кушымта нигезендә « Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районында Күн авылына керү юлында автомобиль юлы төзү » объекты буенча территорияне планлаштыру проектын һәм ызанлау проектын расларга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) һәм Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан (игълан ителгән) көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советының җирлекләрнең җирле үзидарә органнары

белән үзара хезмәттәшлек итү, законлылык, хокук тәртибе һәм регламенты буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Питрәч муниципаль районы башлыгы И.М. Кашапов